КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 23 май г.Казань № 360

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт йөкләмәсе (заказ) урнаштырыла торган дәүләт хезмәтләрен, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә күчү чаралары планын раслау турында» 2021 ел, 13 апрель, 242 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт йөкләмәсе (заказ) урнаштырыла торган дәүләт хезмәтләрен, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә күчү чаралары планын раслау турында» 2021 ел, 13 апрель, 242 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 19 июль, 589 нчы, 2022 ел, 16 февраль, 134 нче, 2022 ел, 29 июль, 726 нчы, 2022 ел, 23 декабрь, 1407 нче, 2023 ел, 13 июль, 826 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Дәүләт йөкләмәсе (заказ) урнаштырыла торган дәүләт хезмәтләрен, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә күчү чаралары планында:

12 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 12.55 пункт өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «12.55. | Йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ үткәрүгә һәм йорт эчендәге газ җиһазын сатып алуга бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирү | 2024 елның 30 сентябре |

14 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 14.11 пункт өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «14.11. | Суны бүлеп чыгаруның үзәкләштерелгән системаларына ташлауларны киметү планын килештерү | 2024 елның 30 сентябре |

әлеге карарга кушымтада:

түбәндәге эчтәлекле 76 һәм 77 пунктлар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «76. | Ясалма җир кишәрлеген булдыру эшләрен уздыруга рөхсәт бирү | 2024 елның 30 сентябре |
| 77. | Ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә тапшыруга рөхсәт бирү | 2024 елның 30 сентябре |

түбәндәге эчтәлекле искәрмә өстәргә:

«Искәрмә. Әлеге исемлекнең 73, 76 һәм 77 пунктларында күрсәтелгән муниципаль хезмәтләр Казан шәһәре муниципаль берәмлеге тарафыннан күрсәтелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин